# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТУЕМБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ГРАЖДАНННАР ҖЫЕНЫ

## КАРАР

25 ноябрь 2024 ел №2

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Кукмара муниципаль районының Туембаш авыл җирлегенең Туембаш авылы гражданнар җыены КАРАР бирэ:

1. 2025 елда Кукмара муниципаль районының Туембаш авыл җирлеге Туембаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылардан һәм студентлардан (курсантлардан), Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрбиләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Туембаш авылының Ленин урамындагы вак таш һәм асфальт түшәлгән юлларны төзекләндерү, ремонтлау һәм төзекләндерү, вак таш сатып алу, проект-смета документлары һәм технадзорны гамәлгә ашыру, Туембаш авылының урам юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, урнаштыру, юлларны төзекләндерү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка төр эшләр);

- ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (зират территориясен карап тоту, киртәләү, төзекләндерү, Туембаш авылындагы зират өчен җиһазлар һәм инвентарь сатып алу, проект-смета документлары, зират территориясен карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка төр эшләр);

-урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (урамнарны яктыртуны карап тоту һәм

урнаштыру, Туембаш авылын урамнарны яктырту өчен светодиодлы лампалар һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документация, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка төр эшләр);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (суүткәргеч челтәрләрен, су җыю манараларын төзү, тоту һәм ремонтлау, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, су җыю манараларын буяу, материаллар сатып алу, Туембаш авылының су саклау зоналарын төзекләндерү, проект-смета документлары, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су җыю манараларын карап тоту буенча башка төр эшләр);
- җир асты сулары чыга торган урыннарны (чишмәләрне) төзекләндерү (Туембаш авылы чишмәләрен төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту, проект-смета документлары, чишмәләрне төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка төр эшләр);
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Туембаш авылында янгын гидрантларын һәм комплектлаучы детальләрне сатып алу, урнаштыру, ремонтлау, карап тоту, проект-смета документлары, янгын гидрантларын һәм комплектлаучы детальләрне ремонтлау һәм карап тоту буенча башка төр эшләр);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (Туембаш авылы территориясен төзекләндерү, агачларны һәм куакларны кисү, килешү буенча эш өчен түләү, территорияне төзекләндерү буенча башка төр эшләр)»

2. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Туембаш авыл җирлеге башлыгы И.Ф. Гарипов

ОГРН 1021607753331
ИНН 1623003900